Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422071, Республика Татарстан,
с. Кильдебяк, ул. Кооперативная, 20а
тел. 45-5-50

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КИЛДЕБӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422071, Татарстан Республикасы
Килдебәк авылы, Кооператив
урамы, 20а йорт
тел. 45-5-50

Kilb.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
26.02.2021

КАРАР
№ 9

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 24.04.2019 ел, №28 карары белән расланган агач һәм куаклар кисүгә, кронлауга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советының 25.02.20021 ел, № 6 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе хакында» нигезләмәне раслау карары нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча берләштерелгән коллегиясенең 04.01.2021 ел №3-ПР беркетмәсен үтәү йөзеннән, Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитетының «муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 24.04.2019 ел, №28 карары белән расланган агач һәм куак кисүгә, кронлауга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1.1. 2.6 пунктның икенче таблицасына түбәндәге эчтәлекле 2) подпункт өстәргә:

2) «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар-Россия

ФСХ.»;

1.2. 2.8 пунктның икенче таблицасына түбәндәге эчтәлекле 5) подпункт өстәргә:

5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

**1.3** 3.4.1 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Башкарма комитет секретаре электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша тәкъдим итү турында запрос җибәрә:

1) күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлар).

2) законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән сорау».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге рәсми сайтында hhttp://saby.tatarstan.ru/kildebiak адресы буенча урнаштырырга.

Килдебәк авыл
җирлеге башлыгы: Н.Н.Заһидуллин